ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.06.2015 Казан ш. № 3-8/э

***«Энерготехснаб» ҖЧҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәрле оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2012 елның 14 декабрендәге 3-11/э санлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында***

«Халыкка һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категорияләренә җибәрү өчен күпләп сату базарында егәрлекне сатып алу күләмнәрен һәм бердәм илкүләм (гомумроссия) электр челтәрләре белән идарә итү оешмасы тарафыннан егәрлекне сатып алу күләмнәрен билгеләү тәртибен камилләштерү максатында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайсыбер актларына кертелүче үзгәрешләрне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 11 маендагы 458 санлы карарына, «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары хуҗаларын территориаль челтәрле оешмаларга кертү турында» 2015 елның 28 февралендәге 184 санлы карарына таянып, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Энерготехснаб» ҖЧҖе һәм «Сетевая компания» ААҖе челтәрле оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2012 елның 14 декабрендәге 3-11/э санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов